СОВЕТ МАЙДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МӘЙДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

23.06.2025г.　　　　с. Майдан　　　　№ 61-308

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Советы бишенче чакырылыш депутатларын сайлауларны билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Мәйдан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 33 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. «Волжская новь» газетасында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның http://pravo.tatarstan рәсми порталында әлеге карарны бастырып чыгарырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районының
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　В.В.Михеев